Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.07. 2019 ел №142

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 нче елның 14 нче сентябрендә кабул ителгән 102 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 01.05.2019 елның 87-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының» Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 89-90 статьясы буенча, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 нче елның 14 нче сентябрендә кабул ителгән 102 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 4 бүлекнең 4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.Гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашында хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә алдагы этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән

билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU), Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә. Кәримов